ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.04.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 982**

«Зеленодольск ш., Бауман ур., 18 адресы буенча һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларында җир кишәрлеген алу турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 14 гыйнварындагы 61 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

ТР Зеленодольск шәһәре Бауман урамындагы 18 нче йортны авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программадан төшереп калдыру сәбәпле, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күпфатирлы йортлары исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 февралендәге 359 номерлы карары нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск шәһәре, Бауман урамы, 18 йорт адресы буенча һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын кулланудан алу турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 14 гыйнварындагы 61 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;
- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ;
- торак урыннарның милекчеләренә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников